ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-74-16, факс:2-62-20, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**4 мая 2018г.**

**№ 300**

Ютазы муниципиципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәтләре өчен түләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы«Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы №195 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтләре өчен түләүдә социаль гарантияләр тәэмин итү һәм аларның хезмәтләрен тәртипкә салу максатында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмаларының (алга таба - аерым оешмалар) җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, катлаулылык һәм киеренкелек өчен өстәмәдән, айлык акчалата бүләкләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләүдән, матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр түләнә торган түләүдән, шулай ук законнар нигезендә башка түләүләрдән тора. Белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакы составына шулай ук һөнәрләрнең бергә кушылуы өчен өстәмә түләүләр, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча эшләмәгән (булмаган) хезмәткәрләрнең вазифаларын үтәү кертелә;

аерым оешмалар эшчеләренең хезмәт хакы айлык тариф ставкасыннан, компенсацион түләүләрдән, эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына өстәмәдән, ел саен түләнә торган түләүле отпускка матди ярдәмнән, класслык өчен машина йөртүчеләргә айлык өстәмә түләүләрдән, вазифаны берләштереп алып барган өчен өстәмә түләүдән, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткән өчен һәм үзенең төп эше белән берләттән вакытлыча эшләми торган хезмәткәрләрнең вазифаларын башкарган өчен түләүләрдән, шулай ук закончалык нигезендә башка түләүләрдән тора;

аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме 11163,0 сум булган күләмгә нисбәтле исәпләнә;

аерым учреждениеләр эшчеләренең айлык тариф ставкалары һәм компенсацион түләүләре күләме Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә.

2. Расларга:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә Бердәм тариф челтәре кагылмый торган вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә бюджет өлкәсенең аерым оешмалары структур бүлекчәләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәт хакы түләү буенча кулланыла торган нисбәт коэффициентын №1 кушымтага ярашлы;

Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары эшчәнлегенә хезмәт күрсәтү белән мәшгуль эшчеләр өчен түләү разрядлары диапазонын №2 кушымтага ярашлы.

3. Аерым оешмалар җитәкчеләренә, белгечләренә һәм хезмәткәрләренә билгеләргә:

1) тиешле елларны эшләгән өчен түбәндәге күләмнәрдә вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүне:

| Хезмәт стажы түбәндәгечә булганда | Айлык өстәмә, процент |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә эшне катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү;

3) вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

4) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

5) еллык түләүле отпуск биргәндә елга вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү.

Әгәр календарь ел дәвамында эшләүче җитәкчегә, белгечкә еллык түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган акча декабрьдә, эшләгән эш вакытына пропорциональ түләнелә һәм эштән азат ителгән очракта - эшнең соңгы көненнән дә соңга калмыйча.

Җитәкчегә, белгечкә еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләнелә торган акча календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән агымдагы календарь елының 31 декабренә кадәр исәпләнә;

6) билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә матди ярдәм.

4. Белгечләргә һәм хезмәткәрләргә вазифаларны берләштереп алып барган өчен, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткән өчен һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча эшләмәгән (булмаган) хезмәткәрләрнең эшен башкарган өчен түләүне хезмәт хакы фонды чикләрендә вазыйфаи окладның 50 процентына кадәр күләмдә билгеләргә.

5. Аерым оешмалар эшчеләренә билгеләргә:

1) нормалаштырылмаган эш көне өчен хезмәт җиңел автомобильләрен йөртүчеләргә айлык тариф ставкасына өстәмә түләүне исәпкә алмыйча, эшнең катлаулылыгын һәм киеренкелеге өчен җиңел автомобиль йөртүчеләрнең айлык тариф ставкасының 50 проценты күләмендә айлык өстәмә түләү;

2) эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

3) еллык түләүле отпуск биргәндә айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмен исәпкә алып, еллык ике айлык тариф ставкасы күләмендә матди ярдәм.

Календарь ел дәвамында эшчегә еллык түләүле отпуск бирелмәгән очракта, еллык түләүле отпуск биргәндә, матди ярдәм аңа декабрьдә, эшләгән вакытына пропорциональ рәвештә түләнә һәм эштән азат ителгән очракта – соңгы эш көненнән соңламыйча.

Эшченең беренче эш елында еллык түләүле отпуск бирелгәндә матди ярдәм календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә

түләнә. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән алып агымдагы календарь елның 31 декабренә кадәр исәпләнә;

4) хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә матди ярдәм;

5) түбәндәге күләмнәрдә хезмәт җиңел автомобильләренең машина йөртүчеләренә классслыгы өчен айлык өстәмә түләү:

1 класслы йөртүчеләргә - машина йөртүче сыйфатында сарыф ителгән вакыт өчен билгеләнгән айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә;

II класслы машина йөртүчеләргә - машина йөртүче сыйфатында файдаланылган вакыт өчен билгеләнгән айлык тариф ставкасының 10 проценты күләмендә;

6) айлык өстәмә түләү:

Вазифаларны берләштереп алып барган, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткән һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча эшләмәгән (булмаган) хезмәткәрләрнең вазифаларын үтәгән өчен - гамәлдәге законнар нигезендә хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә төп эш буенча айлык тариф ставкасының 50 процентка кадәр күләмдә;

төнге вакытта эшләгән өчен (22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр) - сәгать тариф ставкасының 35 проценты күләмендә;

бәйрәм һәм ял көннәрендә эшләгән өчен ике көнлек тариф ставкасы күләмендә;

эш көне нормалаштырылмаган хезмәт өчен җиңел автомобиль йөртүчеләргә - айлык тариф ставкасының 50 процентына кадәр күләмдә.

6. Хезмәткәрләргә федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда каралган башка түләүләрне гамәлгә ашырырга.

7. Аерым оешма җитәкчеләренең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда, вазыйфаи окладларны түләү өчен җибәрелә торган акчалар суммасыннан тыш түләү өчен түбәндәге чаралар каралган дип билгеләргә (елына 12 вазыйфаи окладтан чыгып):

1) тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның җиде проценты күләмендә;

2) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазифаи окладка айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның 10 проценты күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр - вазыйфаи окладларның бер проценты күләмендә;

4) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладларның ике проценты күләмендә;

5) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләү һәм вазыйфаи окладларның 10 проценты күләмендә матди ярдәм.

8. Аерым оешмалар эшчеләренә хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда тариф ставкаларын түләү өчен (компенсация түләүләрен исәпкә алып) җибәрелә торган акчалар суммасыннан тыш түләү өчен түбәндәге акчалар карала (бер елга исәпләгәндә) дип билгеләргә:

1) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмә түләү - бер айлык тариф ставкасы күләмендә;

2) машина йөртүчеләргә классլык өчен, нормага салынмаган эш көне өчен айлык өстәмә тугыз айлык тариф ставкасы күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр - өч айлык тариф ставкасы күләмендә;

4) еллык түләүле ял биргәндә матди ярдәм - айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендәге премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы күләмендә.

9. Аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме, шулай ук аерым оешмалар хезмәткәрләренә айлык һәм башка түләүләр күләмен арту ягына тулы сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш дип билгеләргә.

10. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 4 сентябрендәге "Ютазы муниципаль районының Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалардагы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында"гы " №610 карары үз көчен югалткан дип санарга.

11. Аерым оешма җитәкчеләренә үзләренең локаль норматив актларын әлеге Карарга туры китерергә тәкъдим итәргә.

12. Әлеге Карар 2018 елның 1 апреленнән үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П.Самонина

А.В. Сучкова
2-80-12

Кушымта №1
Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2018 елның 4 маеннан
булган №300 карарына

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕНДӘ БЮДЖЕТ ӨЛКӘСЕНЕҢ АЕРЫМ ОЕШМАЛАРЫ СТРУКТУР БҮЛЕКЧӘЛӘРЕ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕНЕҢ ҺӘМ БЕЛГЕЧЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТ ХАКЫ ТҮЛӘҮ БУЕНЧА БЕРДӘМ ТАРИФ ЧЕЛТӘРЕ КАГЫЛМЫЙ ТОРГАН ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМНӘРЕН ИСӘПЛӘГӘНДӘ КУЛЛАНЫЛА ТОРГАН НИСБӘТ КОЭФФИЦИЕНТЫ

| Вазифа төре | Коэффициент |
|---|---|
| | V төркем |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе | 1,34 |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе урынбасары | 1,30 |
| Бүлек начальнигы | 1,25 |
| Бүлек начальнигы урынбасары | 1,17 |
| Баш белгеч | 1,10 |
| Әйдәүче белгеч | 1,05 |
| I категорияле белгеч | 1,00 |
| II категорияле белгеч | 1,00 |
| Белгеч | 1,00 |

Кушымта №2
Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2018 елның 4 маеннан
булган №300 карарына

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БЮДЖЕТ ӨЛКӘСЕНЕҢ ХЕЗМӘТЛӘРЕНӘ ТҮЛӘҮ БУЕНЧА БЕРДӘМ ТАРИФ ЧЕЛТӘРЕ КАГЫЛМЫЙ ТОРГАН БЮДЖЕТ ӨЛКӘСЕНЕҢ АЕРЫМ ОЕШМАЛАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ БЕЛӘН МӘШГУЛЬ ЭШЧЕЛӘРНЕҢ ХЕЗМӘТЛӘРЕНӘ ТҮЛӘҮ РАЗРЯДЛАРЫ ДИАПОЗОНЫ**

| Һөнәрләр исеме | Хезмәткә түләү разрядлары |
|---|---|
| Гардеробчы, урам җыештыручы, курьер | 1 |
| Каравылчы (вахтер), производство һәм хезмәт бүлмәләрен (биналарын) җыештыручы, лифтчы, кладовщик, йөкче | 1 – 2 |
| Электрон-хисаплау һәм хисаплау машиналары операторы, биналарга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау буенча эшче | 2 – 4 |
| Копировкалау һәм күбәйтү машиналары операторы | 2 – 3 |
| Җиңел автомобиль йөртүче | 4 – 5 |

Искәрмә: Җитештерү һәм хезмәт биналарын җыештыручыларга 2 разрядлы тариф ставкасы җитештерү биналарын, шул исәптән җитештерү калдыкларын, санузелларны һәм җәмәгать бәдрәфләрен җыештырган өчен билгеләнә.

Машина йөртүчеләргә 5 разрядлы тариф ставкасы җиңел автомобильләрнең ике - өч тибында эшләгән очракта, шулай ук автомобильләргә техник хезмәт күрсәтүнең махсуслаштырылган хезмәте булмаган очракта, автомобильне ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү буенча барлык эшләр комплексын башкарган өчен билгеләнә.